МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.06.2016 г.Казань № 177

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 мартындагы 96нчы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының кара металл һәм төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензион контрольне гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәвенең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 3 ноябрендәге Федераль законны тормышка ашыру максатларында **б о е р а м**:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 мартындагы 96нчы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының кара металл һәм төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензион контрольне гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәвенең административ регламентына кертелә торган әлеге боерыкка беркетелгән үзгәрешләрне (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2015 елның 19 мартындагы 135нче, 2015 елның 28 июлендәге 346нчы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән бергә) (алга таба – Административ регламент) расларга.

2. Дәүләт мәгълүмат ресурслары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек бүлегенә (И.С.Сәгыйтов) әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы сайтына урнаштырылуын тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары А.Д.Шәмсиевкә йөкләргә.

Министр в.б. – беренче урынбасар,

Эшкуарлыкны үстерү департаменты директоры Р.Р. Сибгатуллин

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгы
боерыгы белән расланган
02.06.2016 № 177

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 мартындагы 96нчы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының кара металл һәм төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензион контрольне гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәвенең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2015 елның 19 мартындагы 135нче, 2015 елның 28 июлендәге 346нчы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән бергә)

Административ регламентның 1 нче бүлегендә:

1.6 пунктының 1.6.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«1) Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән исемлеккә кертелгән документларны һәм (яки) мәгълүматны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән срокларда һәм тәртиптә әлеге документларга һәм (яки) мәгълүматка ия башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалардан бушлай, шул исәптән электрон формада, соратырга һәм алырга;

2) салым турында яисә закон тарафыннан саклана торган башка яшерен сергә ия документларны һәм (яисә) мәгълүматларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алу түбәндәге шартларда рөхсәт ителә: әгәр тиешле мәгълүматларны тикшерү лицензиягә дәгъва кылучылар, лицензиатлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлеше фактын ачыклау зарурлыгы белән билгеләнсә яисә әлеге мәгълүматны бирү федераль законнарда каралса;

3) документларны һәм (яисә) мәгълүматны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшыруны, аларны ачуны, шул исәптән закон тарафыннан каралган очракларда алар белән танышуны дәүләт һәм закон тарафыннан саклана торган башка серләр турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып башкарырга;

4) лицензиягә дәгъва кылучылар һәм лицензиатларга тикшерүләр үткәрергә, кара металл һәм төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензион контрольне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматларны һәм документларны һәм тапшырылышы Россия Федерациясе законнары белән каралган мәгълүматларны һәм документларны соратырга һәм алырга;

5) лицензиатларга тикшерүләр үткәргәндә ачыкланган лицензион таләпләрне бозуларны юкка чыгару турында кисәтү боерыгы тапшырырга.»;

1.6 пункты 1.6.2 пунктчасының 7 пунктчасында «башка вазыйфаи затның» сүзләрен «башка вазыйфаи зат» сүзләре белән алыштырырга;

1.6 пунктының 1.6.2 пунктчасын түбәндәге эчтәлектәге 14 пунктча белән тулыландырырга:

«14) җитәкчене, башка вазыйфаи затны яисә лицензиягә дәгъва кылучының вәкаләтле вәкилен, лицензиатны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яисә) мәгълүмат белән таныштырырга.»;

1.6 пунктының 1.6.3 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле 10 һәм 11 пунктчалары белән тулыландырырга:

«10) лицензиягә дәгъва кылучыдан, лицензиаттан Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән исемлеккә кертелгән, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнары яки җирле үзидарә буйсынуындагы оешмалардан документлар һәм (яисә) мәгълүмат (рөхсәт бирү документларын да кертеп) тапшыруын таләп итәргә (әлеге абзац таләбе 2017 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә);

11) лицензиягә дәгъва кылучыдан, лицензиаттан элегрәк Россия Федерациясе законнарына ярашлы рәвештә тапшырылган һәм (яки) дәүләт яисә муниципаль мәгълүмат системаларында, реестрларында һәм регистрларында булган мәгълүматны тапшыруны таләп итәргә (әлеге абзац таләбе 2017 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә).»;

1.7 пунктының 1.7.1 пунктчасын түбәндәге эчтәлектәге 6, 7 һәм 8 пунктчалары белән тулыландырырга:

«6) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында әлеге документларга һәм (яки) мәгълүматка ия башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалардан Министрлык тарафыннан алынган документлар һәм (яки) мәгълүмат белән танышырга;

7) үз инициативасы буенча Министрлыкка ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратыла торган документларны һәм (яки) мәгълүматны тапшырырга;

8) тикшерү планлы тикшерүләрнең еллык планына 294-ФЗ номерлы Федераль законның 26.1 маддәсен бозып планлы тикшерүләрнең еллык планына кертелгән дип исәпләгән очракта үзләренә карата тикшерүне планлы тикшерүләрнең еллык планыннан алу турында Министрлыкка гариза тапшырырга.»;

Административ регламентның 2 бүлеге 2.4 пунктының 2.4.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге икенче абзац белән тулыландырырга:

«2016 елның 1 гыйнварыннан 2018 елның 31 декабренә кадәр чорда «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 4 маддәсе нигезләмәләренә ярашлы рәвештә кече эшкуарлык субъектларына кертелгән юридик затлар һәм шәхси эшкуарларга карата планлы тикшерүләр 294-ФЗ номерлы Федераль законның 26.1 маддәсе таләпләренә ярашлы рәвештә оештырыла һәм үткәрелә»;

Административ регламентның 3 бүлегенең 1 таблицасындагы «Тикшергәндә лицензиягә дәгъва кылучылар, лицензиатлар тарафыннан күрсәтелә торган документлар исемлеге» графасын 4 сан белән номерларга;

Административ регламентның 5 бүлегендә:

преамбулада:

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«294-ФЗ номерлы Федераль законның 13 маддәсе 2 өлешендә күрсәтелгән тикшерүне үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документлар һәм (яки) мәгълүмат алу зарурлыгы туган очракта тикшерүне үткәрү Министрлык министры (министр урынбасары) тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне гамәлгә ашырырга кирәк булган срокка туктатылырга мөмкин, әмма ун эш көненнән дә озагракка түгел. Тикшерүне үткәрүне кабат туктату рөхсәт ителми (әлеге абзац таләбе 2016 елның 1 июленнән гамәлгә керә).»;

түбәндәге эчтәлектәге унынчы абзац белән тулыландырырга:

«Тикшерүне үткәрүне туктату гамәлдә булган вакытта Министрлыкның кече эшкуарлык субъекты территориясендә, биналарда, корылмаларда, бүлмәләрдә һәм башка объектларда әлеге тикшерүгә бәйле гамәлләре туктатыла (әлеге абзац таләбе 2016 елның 1 июленнән гамәлдә)»;

5.1 пунктының 5.1.5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Җаваплы башкаручы планлы күчмә тикшерүне үткәрү турында лицензиатка планлы күчмә тикшерүне үткәрү турында боерык күчермәсен почта элемтәсе аша иясенә тапшырылу хакында белдерү кәгазе беркетелгән заказлы хат юллау яисә башка мөмкин булган ысул белән хәбәр итә.

Планлы документар тикшерү үткәрү алдыннан Министлыкның вазыйфаи затлары җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яисә лицензиатның вәкаләтле вәкиленә, аның вәкаләтле вәкиленә 294-ФЗ номерлы Федераль законның 26.1 маддәсе нигезләмәләре эчтәлеген аңлаталар.

Башкару срогы: планлы күчмә тикшерүне үткәрү алдыннан өч эш көненнән дә соңга калмый.

Гамәлнең нәтиҗәсе: лицензиат адресына юлланган планлы күчмә тикшерүне үткәрү турында боерык күчермәсе.

Планлы күчмә тикшерүне үткәрү турында боерык күчермәсен лицензиат адресына юллау Министрлыкта эш башкаруларны алып бару кагыйдәләренә ярашлы рәвештә билгеләнгән тәртиптә теркәлә.»;

5.1 пунктының 5.1.7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

Җаваплы башкаручы контроль буенча түбәндәге чараларны үткәрә:

- лицензиат эшчәнлегенең әлеге Регламентның 3 бүлегендә китерелгән мәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяли;

- планлы күчмә тикшерү актын тутыра.

Планлы күчмә тикшерү вакытында лицензиат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең бозылуы ачыкланган очракта җаваплы башкаручы түбәндәгеләрне эшли:

- тикшерүләр актында ачыкланган хилафлыкларның барлык очракларын терки;

- ачыкланган хилафлыкларны юкка чыгару турында һәм ачыкланган хилафлыкларны юкка чыгару, аларны кисәтү һәм булдырмый калу буенча чаралар күрү зарурлыгы турында кисәтү боергы тапшыру турында карар кабул итә, бу вакытта кабул ителә торган карар критерие булып ачыкланган хилафлыклар, аларны бәяләү тора;

- лицензиатка ачыкланган хилафлыкларның юкка чыгару сроклары күрсәтелгән хилафлыкларны юкка чыгару турында һәм (яки) кеше тормышына, сәламәтлегенә зыян салуны, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирaслары объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), дәүләт иминлегенә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт һәм муниципаль мөлкәткә зыян китерүне, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрнең килеп чыгуын кисәтү буенча, һәм шулай ук федераль законнарда каралган башка чараларны үткәрү турында кисәтү боерыгы тапшыра;

- ачыкланган хилафлыкларны юкка чыгаруга, аларны кисәтү, гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирасы объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә) ихтимал булган зарар китерүне булдырмый калуга, дәүләт иминлеген тәэмин итү, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрнең килеп чыгышын кисәтүгә контрольлек итү буенча чаралар күрә.

Тикшерү акты планлы күчмә тикшерү узуга ук ике нөсхәдә төзелә, берсе лицензиатка акт белән танышу яисә танышудан баш тарту турында кул куйдырып тапшырыла.

Җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә лицензиатның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, һәм шулай ук лицензиатның тикшерү акты белән танышу турында кул куюдан яисә танышудан баш тарту очрагында тикшерү акты почта элемтәсе аша иясенә тапшырылу хакында белдерү кәгазе беркетелгән заказлы хат белән лицензиатка юллана һәм лицензия эшендә саклана торган тикшерү актына теркәлә.

Тикшерелә торган затның лицензион контроль кысаларында үзара эш итүне электрон формада башкаруга ризалыгы булган очракта, тикшерү акты җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яисә лицензиатның вәкаләтле вәкиленә әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документ формасында да юлланырга мөмкин. Бу вакытта тикшерелүче затка әлеге документны алуны раслауны тәэмин итә торган ысул белән, актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документ формасында юлланган акт тикшерүче зат тарафыннан алынган дип санала.

Тикшерү актын төзү өчен, тикшеренүләр, сынаулар, махсус эшләнүләр, экспертизалар үткәреп, аларның нәтиҗәләре буенча бәяләмә алырга кирәк булган очракта, тикшерү акты контроль буенча чаралар тәмамланганнан соң өч эш көненнән дә соңга калмый төзелә һәм җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яисә лицензиатның вәкаләтле вәкиленә имза куйдырып тапшырыла яки почта элемтәсе аша иясенә тапшырылу хакында белдерү кәгазе беркетелгән заказлы хат белән һәм (яисә) актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документ формасында әлеге документны алуны раслауны тәэмин итә торган ысул белән да юллана (тикшерелә торган затның лицензион контроль кысаларында үзара эш итүне электрон формада башкаруга ризалыгы булган очракта). Бу вакытта тапшыру турында хәбәр һәм (яисә) әлеге документны алу турында башка раслау кәгазе Министрлыктагы лицензия эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә.

Җаваплы башкаручы тикшерүләрне исәпкә алу журналына (ул булган очракта) үткәрелгән тикшерү турында язып куя. Аңа дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы атамасы турында мәгълүмат, тикшерүне башлау һәм тәмамлау даталары, аны үткәрү вакыты, хокукый нигезләре, тикшерүнең максаты, бурычлары һәм предметы, ачыкланган хилафлыклар һәм бирелгән кисәтү боерыгы турында мәгълүмат керә, һәм шулай ук тикшерүне үткәргән вазыйфаи затның яисә вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм вазыйфалары, аның яисә аларның имзалары теркәп куела. Тикшерүләрне исәпкә алу журналының

типлаштырылган формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141нче боерыгы белән билгеләнгән.

Тикшерү үткәрелгән лицензиат тикшерү актында бирелгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр яисә ачыкланган хилафлыкларны юкка чыгару турындагы кисәтү боерыгы белән ризалашмаган очракта, тикшерү актын алган көннән соңгы унбиш көн эчендә Министрлыкка тикшерү актына һәм (яисә) ачыкланган хилафлыкларны юкка чыгару турында алынган кисәтү боерыгына тулаем яисә аның аерым нигезләмәләренә карата үзенең каршы булуын язмача формада белдерә ала. Бу вакытта лицензиат мондый язмага әлеге ризасызлыкны раслаучы документларны яисә аларның таныкланган күчермәләрен килештерелгән срокта Министрлыкка тапшырырга хокуклы. Әлеге документлар тикшерелгән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланып, электрон документ (электрон документ пакеты) формасында юллана ала.

Башкарылу срогы: планлы күчмә тикшерү үткәрү турындагы боерыкта күрсәтелгән срокларда, әмма тикшерүне үткәрү башланганнан соң егерме эш көненнән дә артыграк түгел; тикшерү актын тапшыру, имза куйдырылып, планлы күчмә тикшерү тәмамлануга яисә элемтәсе аша иясенә тапшырылу хакында белдерү кәгазе беркетелгән заказлы хат белән яисә актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документ формасында: тикшерү акты төзелгәннән соңгы беренче эш көне эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: үткәрелгән планлы күчмә тикшерү, тикшерү акты, тикшерүләрне исәпкә алу журналында үткәрелгән планлы күчмә тикшерү турында язу;

хилафлыклар ачыкланганда – ачыкланган хилафлыкларны юкка чыгару турында кисәтү боерыгы.

Җаваплы башкаручы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару тәртибе турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415нче Карарына ярашлы рәвештә тиешле мәгълүматны тикшерүләрнең бердәм реестрына кертә (әлеге абзац таләбе 2016 елның 1 июленнән гамәлгә керә).»;

5.2 пунктының 5.2.7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат хатта (нигезләнгән гарызнамәдә) күрсәтелгән документларның лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиатның мөһере (ул булганда) һәм имзасы белән таныкланган күчермәләрен тапшыра. Лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат хатта (нигезләнгән гарызнамәдә) күрсәтелгән документларны Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында тапшырырга хокуклы.

Министрлык тикшерүләрне оештырганда һәм үткәргәндә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән исемлеккә кертелгән документларны һәм (яисә) мәгълүматны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән срокларда һәм тәртиптә әлеге документларга һәм (яисә) мәгълүматка ия башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалардан бушлай, шул исәптән электрон формада, сората һәм ала (әлеге абзац таләбе 2016 елның 1 июленнән гамәлгә керә).

Тапшырылган документларда ачыкланган хаталарга һәм (яисә) каршылыкларга карата яки әлеге документлардагы мәгълүматның Министрлыкта булган документлардагы мәгълүматка туры килмәвенә карата Министрлыкка аңлатма бирүче лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат өстәмә рәвештә Министрлыкка элегрәк тапшырылган документларның дөреслеген раслаучы документларны китерергә хокуклы.

Җаваплы башкаручы лицензиягә дәгъва кылучының, лицензиатның башка вазыйфаи заты  яисә җитәкче тарафыннан тапшырылган аңлатмаларны һәм (яисә) элегрәк бирелгән документларның дөреслеген раслаучы документларны карарга тиеш. Әгәр Министрлык бирелгән аңлатмаларны һәм документларны караганнан соң яисә аңлатмалар булмыйча, мәҗбүри таләпләрнең сакланмавы билгеләрен табыла икән, Министрлыкның вазыйфаи заты (вазыйфаи затлары) планнан тыш күчмә тикшерү үткәрергә хокуклы.

Җаваплы башкаручы күчмә тикшерү уздыруның таләп ителүе  яисә аның таләп ителмәве турында карар кабул итә. Лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат тарафыннан тапшырылган аңлатмаларны һәм (яисә) документларны карау барышында  әлеге Регламентның 5.3 бүлегенә ярашлы рәвештә күчмә тикшерү үткәрү өчен нигез булып хезмәт итүче лицензион таләпләрнең бозылуы билгеләре күчмә тикшерү үткәрүнең кирәклеге турында карар кабул итүнең критерие булып тора.

Планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрүнең кирәклеге турында карар кабул ителгән очракта җаваплы башкаручы планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында боерык проектын әзерли.

Башкару срогы: аңлатманы һәм (яисә) документларны алганнан соң ике эш көне эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: җаваплы башкаручы тарафыннан каралган  лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат тарафыннан тапшырылган аңлатмалар һәм (яисә) документлар;

таләп ителгәндә, планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында боерык проекты.»;

Административ регламентка 1нче Кушымтаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«Татарстан Республикасы Икътисад
министрлыгының кара металл һәм төсле
металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү
һәм сату өлкәсендә лицензион контрольне
гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен
үтәвенең административ регламентына
1нче Кушымта

Форма

# Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы

ачыкланган хилафлыкларны юкка чыгару турында

**КИСӘТҮ БОЕРЫГЫ №**

Казан ш. «__»___________20__ел

Бирелде ______________________________________________________________,

(юридик затның атамасы, шәхси эшкуарның Ф.И.О.)

Юридик затның урнашкан урыны (шәхси эшкуарның яшәү урыны адресы) ________________________________________________________________,

Салым түләүченең идентификация номеры (ИНН) ___________________________,

Дәүләт теркәве турында язманың төп дәүләт теркәү номеры ________________________________________________________________

(ОГРН – юридик зат өчен, ОГРНИП – шәхси эшкуар өчен)

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 20__ елның «___»_____________ ___нче боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы Административ реформа мәсьәләләре идарәсенең лицензияләү бүлеге вазыйфаи затлары тарафыннан: _____________________________________________,

(Ф.И.О., вазыйфасы)

түбәндәге адрес буенча урнашкан__________________________________________

территориаль аерымланган объектларга планлы күчмә тикшерү үткәрелде ________________________________________________________________.

(юридик затның атамасы, шәхси эшкуарның Ф.И.О.)

Планлы тикшерү нәтиҗәләре буенча акт төзелде №___ 20__ елның «__»______, имзаланды_____________________________________________________.

(юридик затның, шәхси эшкуарның вәкаләтле вәкиле Ф.И.О.)

Тикшерү актының икенче нөсхәсе имза куелып алынды ___________________________________________________________________.

(юридик затның, шәхси эшкуарның вәкаләтле вәкиле Ф.И.О.)

Планлы тикшерү барышында: _________________________________.

(закон бозу эчтәлеге, НПА күрсәтелә)

«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның 19 маддәсе 1 пунктына; «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2006 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 17 маддәсе 1 пунктына ярашлы рәвештә кисәтәм:

1. Лицензион таләпләрне үтәүне раслап, югарыда аталган хилафлыкларны юкка чыгарырга: _____________________________________________________

(лицензион таләпләрнең исемлеге)

2. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына әлеге кисәтүне үтәү турында язма формада хәбәр итәргә һәм аның үтәлешен раслаучы документларның күчермәләрен тапшырырга, срогы 20__ елның «___» _____ кадәр.

Министр (министр урынбасары)_______________ ____________________

(имза) (Ф.И.О.) ».